КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 сентябрь г.Казань № 974

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 сентябрь, 851 нче карары белән расланган «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 9 сентябрь, 851 нче карары

белән расланган «Казан – Болгар – Казан» һәм (яки) «Казан – Свияжск – Казан» муниципальара даими йөртүләр маршрутлары буенча автомобиль транспорты белән пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшмәкәрләр алып бетермәгән керемнәрне каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлык, заявкалар кабул ителә башлаган көнгә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, бердәм порталда һәм сайтта, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү (алга таба – белдерү) урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 20 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Нигезләмәнең 8 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм сайлап алуда катнашучылар тарафыннан аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 10 – 14 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

бердәм порталда һәм сайтта, сайлап алуда җиңүчеләр билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.»;

8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы белдерүдә күрсәтелгән срокта Министрлыкка, түбәндәге документларны теркәп, заявка тапшыра:

муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртүне һәм багажлар ташуны

гамәлгә ашыру турындагы таныклыклар күчермәләрен;

сайлап алу үткәрелә торган айга кадәрге айда муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртүнең һәм багажлар ташуның күләмнәрен раслый торган юл йөрү кәгазьләре һәм билетны исәпкә алу документацияләре күчермәләрен;

сайлап алуда катнашучының заявка бирелә торган датага кадәр 15 эш көненнән артмаган датага салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган, салым органы тарафыннан бирелгән белешмә кәгазен (әгәр әлеге документ сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылмаган булса, Министрлык аны салым органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала);

сайлап алуда катнашучының Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычы һәм Татарстан Республикасы каршында акчалата йөкләмәләр буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазен;

сайлап алуда катнашучының үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавын, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәве, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмавын, ә сайлап алуда катнашучы индивидуаль эшмәкәрнең үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазен;

сайлап алуда катнашучының чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазен;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максат өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазен;

сайлап алуда катнашучының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучы тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) сугылган белешмә кәгазен;

Тапшырылган документларның күчермәләре сайлап алуда катнашучы тарафыннан расланырга һәм аңа мөһер сугылырга тиеш (булганда).

Сайлап алуда катнашучы бирелгән заявкадагы һәм документлардагы мәгълүматның дөреслеге өчен җавап бирә.»;

15 пунктта:

бишенче абзацта «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә), шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы;»;

20 пунктның бишенче абзацында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе күрсәткечләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23. Министрлык субсидия алучының субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

түбәндәге эчтәлекле $23^1$ пункт өстәргә:

«$23^1$. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.».

2. Тәртипнең 8 пунктындагы өченче абзацының һәм 9 пунктындагы бишенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы кырыгынчы абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин